ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының өченче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының өченче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында.
4. М.А. Җаббаровны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп билгеләүне килештерү турында.
5. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы итеп үзгәртү турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимен килештерү турында.
6. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 614-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 619-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 613-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 618-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «2020 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» 616-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «2020 елга Татарстан Республикасында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 611-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «2020 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 612-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 615-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 610-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 621-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2020 елга пенсионерның яшәү минимумы

күләмен билгеләү турында» 617-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Кредит тарихлары турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

18. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 48 статьясына үзгәреш кертү турында» 751723-7 номерлы федераль закон проекты хакында (физик затлардан салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны түләттерү тәртибен үзгәртү өлешендә).

19. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 755219-7 номерлы федераль закон проекты турында (сәүдә объектына идарә итә торган компаниягә һәм аның вазыйфаи затларына сәүдә эшчәнлеген шундый объектта башкарганда кулланучыларның хокукларын саклауны тәэмин итмәгән өчен җаваплылык билгеләү өлешендә).

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $2.6^{1}$ статьясына үзгәреш кертү хакында» 743069-7 номерлы федераль закон проекты турында (фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләре булган махсус техник чараларга яисә автомат режимда эшли торган фото һәм кино төшерү, видеоязма чараларына карата таләпләр билгеләү хакында).

21. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 8 статьясына муниципаль округлар территорияләрендә гражданнарны хәрби исәпкә алуны камилләштерүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 750505-7 номерлы федераль закон проекты турында (территориясендә беренчел хәрби исәпкә алу гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекләрне төгәлләштерү өлешендә).

22. «Россия Федерациясендә исәп-хисапларны гамәлгә ашырганда контроль-касса техникасын куллану турында (муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан контроль-касса техникасын куллану үзенчәлеге өлешендә)» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 761631-7 номерлы федераль закон проекты турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 20 сентябре
№ 45-VI ДС